ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУРНАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӨРНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Коры Көрнәле ав.

08.09.2026 № 13

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының 14.11.2022 ел, № 19 «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законның 4 һәм 19_5 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 15 һәм 15_1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 25 маендагы 552-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатында,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының 14.11.2022 ел,№ 19 «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

- 2.14.2. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.14.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә:

1) туристлык эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә классификацияләнергә тиешле социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарына, корылмаларга һәм төзелмәләргә, физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашканнарын да кертеп), туристлык индустриясе объектларына ("Кунак йортлары хезмәтләрен күрсәтү буенча эксперимент үткәрү турында" 2025 елның 7 июнендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урнаштыру чараларына караган объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш)(алга таба - туристлык индустриясе объектлары), ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә карый торган объектларга тоткарлыксыз керү өчен шартлар ;

2) шәһәр, шәһәр яны, шәһәрара юлларда тимер юл, һава, су транспортыннан, автомобиль транспортыннан һәм шәһәр жир өсте электр транспортыннан, элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан (светофорларның һәм транспорт коммуникацияләре аша җәяүлеләр хәрәкәтен җайга сала торган җайланмаларның яктылык сигналларының тавыш сигналлары белән кабатлануын тәэмин итә торган чараларны да кертеп)тоткарлыксыз файдалану шартлары;

3) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары, туристлык индустриясе объектлары урнашкан территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып, мөмкин булуы;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларында, туристлык индустриясе объектларында күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына, туристлык индустриясе объектларына һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне аларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язмаларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктал Брайль шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

7) халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган махсус өйрәтүне раслый торган һәм форма буенча һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына, туристлык индустриясе объектларына йөртүче этне кертү;

8) халыкка хезмәт күрсәтүче оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуга комачаулый торган киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Д.Б Казаковага йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **Казакова Д.Б.**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АЛЕКСЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Р06-1644/13
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1605004958 ОГРН 1061677003410